МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.04.2021 Казан ш. № 18-33

Бурычын түләү мөмкинлеге уртача яки түбән дәрәҗәдәге займчылар төркеменә кертелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга (чираттагы финанс елына) муниципаль эчке һәм тышкы займ, чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга (чираттагы финанс елына) муниципаль гарантияләр программаларын, шулай ук әлеге программаларга үзгәрешләрне килештерү өчен кирәкле документларны һәм материалларны тапшыру тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107.1 статьясындагы 7 пункты һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31.1 статьясындагы 5 пункты нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

1. Бурычын түләү мөмкинлеге уртача яки түбән дәрәҗәдәге займчылар төркеменә кертелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга (чираттагы финанс елына) муниципаль эчке һәм тышкы займ, чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга (чираттагы финанс елына) муниципаль гарантияләр программаларын, шулай ук әлеге программаларга үзгәрешләрне килештерү өчен кирәкле документларны һәм материалларны тапшыру тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары А.Г. Шишкинга йөкләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
23.04.2021 № 18-33
боерыгы белән расланды

Бурычын түләү мөмкинлеге уртача яки түбән дәрәҗәдәге займчылар төркеменә кертелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга (чираттагы финанс елына) муниципаль эчке һәм тышкы займ, чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга (чираттагы финанс елына) муниципаль гарантияләр программаларын, шулай ук әлеге программаларга үзгәрешләрне килештерү өчен кирәкле документларны һәм материалларны тапшыру тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107.1статьясы нигезендә бурычын түләү мөмкинлеге уртача яки түбән дәрәҗәдәге займчылар төркеменә кертелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга (чираттагы финанс елына) муниципаль эчке һәм тышкы займ, чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга (чираттагы финанс елына) муниципаль гарантияләр программаларын (алга таба – муниц ипаль займнар, муниципаль гарантияләр программалары), шулай ук әлеге программаларга үзгәрешләрне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан килештерү өчен кирәкле документларны һәм материалларны тапшыру процедурасын билгели.

2. Муниципаль берәмлекләр Министрлыкка тапшыра:

2.1. муниципаль займнар, муниципаль гарантияләр программаларын килештерү өчен:

чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турында карар проектын (чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турында карага үзгәрешләр проектын);

чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга (чираттагы финанс елына) бурыч сәясәтенең төп юнәлешләре проектын (чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга (чираттагы финанс елына) бурыч сәясәтенең төп юнәлешләре);

Бу Тәртипкә № 1кушымта нигезендәге форма буенча мәгълүматларны;

2.2. муниципаль займнар, муниципаль гарантияләр программаларына үзгәрешләрне килештерү өчен:

агымдагы финанс елына һәм планда каралган чорга (агымдагы финанс елына) җирле бюджет турында карарның гамәлдәге редакциясен һәм җирле бюджет турында карарга үзгәрешләр проектын;

агымдагы финанс елына һәм планда каралган чорга (агымдагы финанс елына) бурыч сәясәтенең төп юнәлешләрен;

бу Тәртипкә №2 кушымта нигезендәге форма буенча мәгълүматларны.

3. Муниципаль займнар, муниципаль гарантияләр программаларын килештерү өчен документлар һәм материаллар Министрлыкка агымдагы финанс елының 15 ноябреннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Муниципаль займнар, муниципаль гарантияләр программаларына үзгәрешләрне килештерү өчен документлар һәм материаллар Министрлыкка, җирле бюджет турында үзгәрешләр проекты вәкиллекле муниципаль берәмлек органына кертелгәнче, тапшырыла.

4. Министрлык бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән документлар һәм материаллар алынганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмаган вакыт эчендә аларны карап тикшерә һәм карап тикшерү нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлеккә муниципаль займнар, муниципаль гарантияләр программаларын яки бу программаларга үзгәрешләрне килештерү турында бәяләмә, яисә муниципаль займнар, муниципаль гарантияләр программаларын яки бу программаларга үзгәрешләрне килештерүдән баш тарту турында бәяләмә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, җибәрә.

5. Муниципаль займнар, муниципаль гарантияләр программаларын яки бу программаларга үзгәрешләрне килештерүдән баш тартуга нигезләр булып тора:

1) бурычын түләү мөмкинлеге уртача дәрәҗәдәге займчылар төркеменә кертелгән муниципаль берәмлекнең Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 статьясындагы 19 пункты, 106 статьясындагы 2 һәм 4 пунктлары таләпләрен үтәмәве;

2) бурычын түләү мөмкинлеге түбән дәрәҗәдәге займчылар төркеменә кертелгән муниципаль берәмлекнең Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 статьясындагы 23-25 пунктлары, 106 статьясындагы 2 һәм 4 пунктлары таләпләрен үтәмәве.

6. Кабат җибәрелгән документлар һәм материаллар яңа алынган булып санала һәм бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән вакыт эчендә карала.

Бурычын түләү мөмкинлеге уртача яки түбән дәрәҗәдәге займчылар төркеменә кертелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга (чираттагы финанс елына) муниципаль эчке һәм тышкы займ, чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга (чираттагы финанс елына) муниципаль гарантияләр программаларын, шулай ук әлеге программаларга үзгәрешләрне килештерү өчен кирәкле документларны һәм материалларны тапшыру тәртибенә №1 кушымта

Бюджетның төп параметрлары турында
МӘГЪЛҮМАТЛАР

________________________________,
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге атамасы)

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан муниципаль эчке һәм тышкы займнар программаларын, шулай ук муниципаль гарантияләр программаларын килештерү турында карар кабул итү өчен кирәкле

(мең сумнарда)

| | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты турында карар проектында күздә тотылган күрсәткеч | Чираттагы финанс елы | Планда каралган чорның беренче елы | Планда каралган чорның икенче елы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ел азагына муниципаль бурычның планда күздә тотылган күләме | | | |
| 2 | Кире кайтарылмый торган керемнәрдән һәм (яки) физик затлар керемнәренә салымнан чигерүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәрен исәпкә алмыйча, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең пландагы гомуми күләме | | | |
| 3 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренең планда күздә тотылган күләме | | | |
| 4 | Россия Федерациясе бюджеты системасы бюджетларыннан бирелә торган дотациянең планда күздә тотылган күләме | | | |
| 5 | Россия Федерациясе бюджеты системасы бюджетларыннан бирелә торган субвенцияләрнең планда күздә тотылган | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | күләме | | | |
| 6 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге чыгымнарының планда күздә тотылган гомуми күләме | | | |
| 7 | Җирле бюджет дефицитының (профицит) планда күздә тотылган күләме | | | |
| 8 | Муниципаль бурыч йөкләмәләрен түләүгә җибәрелә торган муниципаль займнар күләме | | | |
| 9 | Бюджет дефицитын финанслауга җибәрелә торган муниципаль займнар күләме | | | |
| 10 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең тиешле финанс елының 1 гыйнварына барлыкка килгән муниципаль бурычын каплау буенча түләүләрнең гомуми суммасы, тиешле финанс елыннан соң килүче елның 1 гыйнварыннан соң каплау срогы белән бурыч йөкләмәләрен вакытыннан алда каплауга җибәрелә торган түләүләрдән тыш | | | |
| 11 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең тиешле финанс елының 1 гыйнварына барлыкка килгән муниципаль бурычын түләү буенча түләүләрнең гомуми суммасы, тиешле финанс елыннан соң килүче елның 1 гыйнварыннан соң каплау срогы белән бурыч йөкләмәләрен вакытыннан алда каплауга җибәрелә торган түләүләрдән тыш | | | |
| 12 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычын түләү чыгымнарының планда күздә тотылган күләме | | | |
| 13 | 1 елга һәм аннан кимрәк вакытка җәлеп итүгә планлаштырыла торган бурыч йөкләмәләре күләме, финанс елы дәвамында җирле бюджет счетындагы средстволар калдыкларын тулыландыру өчен Россия Федерациясе бюджеты системасының башка бюджетларыннан җәлеп ителгән бюджет кредитларыннан тыш | | | |

Татарстан Республикасы муниципаль
берәмлегенең финанс органы җитәкчесе ________________ ______________________________

М.У. (имза) (тулы имза)

Бурычын түләү мөмкинлеге уртача яки түбән дәрәҗәдәге займчылар төркеменә кертелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга (чираттагы финанс елына) муниципаль эчке һәм тышкы займ, чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга (чираттагы финанс елына) муниципаль гарантияләр программаларын, шулай ук әлеге программаларга үзгәрешләрне килештерү өчен кирәкле документларны һәм материалларны тапшыру тәртибенә №2 кушымта

Бюджетның төп параметрлары турында
МӘГЪЛҮМАТЛАР

______________________________,
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге атамасы)

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан муниципаль эчке һәм тышкы займнар программаларына, шулай ук муниципаль гарантияләр программаларына үзгәрешләрне килештерү турында карар кабул итү өчен кирәкле

Таблица 1

(мең сумнарда)

| | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты турында карар проектында күздә тотылган күрсәткеч | Агымдагы финанс елы | Планда каралган чорның беренче елы | Планда каралган чорның икенче елы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ел азагына муниципаль бурычның планда күздә тотылган күләме | | | |
| 2 | Кире кайтарылмый торган керемнәрдән һәм (яки) физик затлар керемнәренә салымнан чигерүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәрен исәпкә алмыйча, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең планда күздә тотылган гомуми күләме | | | |
| 3 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренең планда күздә тотылган күләме | | | |
| 4 | Россия Федерациясе бюджеты системасы бюджетларыннан бирелә торган дотациянең планда күздә тотылган күләме | | | |
| 5 | Россия Федерациясе бюджеты системасы бюджетларыннан бирелә торган | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | субвенцияләрнең планда күздә тотылган күләме | | | |
| 6 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге чыгымнарының планда күздә тотылган гомуми күләме | | | |
| 7 | Җирле бюджет дефицитының (профицит) планда күздә тотылган күләме | | | |
| 8 | Муниципаль бурыч йөкләмәләрен түләүгә җибәрелә торган муниципаль займнар күләме | | | |
| 9 | Бюджет дефицитын финанслауга җибәрелә торган муниципаль займнар күләме | | | |
| 10 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең тиешле финанс елының 1 гыйнварына барлыкка килгән муниципаль бурычын каплау буенча түләүләрнең гомуми суммасы, тиешле финанс елыннан соң килүче елның 1 гыйнварыннан соң каплау срогы белән бурыч йөкләмәләрен вакытыннан алда каплауга җибәрелә торган түләүләрдән тыш | | | |
| 11 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең тиешле финанс елының 1 гыйнварына барлыкка килгән муниципаль бурычын түләү буенча түләүләрнең гомуми суммасы, тиешле финанс елыннан соң килүче елның 1 гыйнварыннан соң каплау срогы белән бурыч йөкләмәләрен вакытыннан алда каплауга җибәрелә торган түләүләрдән тыш | | | |
| 12 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычын түләү чыгымнарының планда күздә тотылган күләме | | | |
| 13 | 1 елга һәм аннан кимрәк вакытка җәлеп итүгә планлаштырыла торган бурыч йөкләмәләре күләме, финанс елы дәвамында җирле бюджет счетындагы средстволар калдыкларын тулыландыру өчен Россия Федерациясе бюджеты системасының башка бюджетларыннан җәлеп ителгән бюджет кредитларыннан тыш | | | |

Татарстан Республикасы муниципаль
берәмлегенең финанс органы җитәкчесе ______________ ______________________________

(имза) (тулы имза)

М.У.

Таблица 2

(мең сумнарда)

| | Күрсәткеч | Хисап финанс елы |
|---|---|---|
| 1 | Җирле бюджет дефициты (профициты) күләме | |
| 2 | Муниципаль бурыч йөкләмәләрен каплауга җибәрелә торган муниципаль займнар күләме | |
| 3 | Бюджет дефицитын финанслауга җибәрелә торган муниципаль займнар күләме | |

Татарстан Республикасы муниципаль
берәмлегенең финанс органы җитәкчесе ______________ ______________________________

(имза) (тулы имза)

М.У.